| Республика Татарстан<br>Иляксазское сельское<br>поселение Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районынын Илексаз<br>авыл жирлеге |
|---|---|
| **КАРАР**<br>**19.12.2025 ел** | **КАРАР**<br>**№ 25** |

Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтеры хезмәтенә түләү шартлары турында» 2024 елның 24 июнендәге 8нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтеры хезмәтенә түләү шартлары турында» 2024 елның 24 июнендәге 8 номерлы карарына (2024 нең 1 ноябрендәге 13 номерлы, 2025 елның 30 апрелендәге 8 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерның вазыйфаи окладын түбәндәге үлчәмнәрдә билгеләнә:

| Вазифасы | 3,5 мең кешегә кадәр халык саны булган башкарма комитет |
|---|---|
| Баш бухгалтер | - |
| Бухгалтер | 29 000 рублей |

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә игълан итәргә.
3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.Х.Хадиуллин